**Министерство образования и науки Республики Татарстан**
**Казанский (Приволжский) федеральный университет**
**Отдел образования Управления образования ИКМО г. Казани по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам**
**Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов Ново-Савиновского района г.Казани**

# *ЛИСТАЯ СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ…*

**Республиканские педагогические чтения, посвященные выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям**

**Казань – 2022**

УДК 372.882.512.145
ББК 74.268.3(2Рос=Тат)
Л

***Редакторы:***

**Т.Р.Шакирова**, Заслуженный учитель Татарстана, директор высшей квалификационной категории муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани;

**Р.Р.Кашапова**, заместитель директора высшей квалификационной категории по вопросам национального образования муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани

**Листая страницы истории…:** Республиканские педагогические чтения, посвященные выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям. – Казань, редакционно-издательский центр «Школа», 2022. – 340 с.

В сборник включены тезисы научно-исследовательских работ учителей школ г.Казани и республики, представленных на Республиканских педагогических чтениях, посвященных выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям. Сборник адресован преподавателям общеобразовательных организаций.

*Материалы печатаются в авторской редакции*

© Коллектив авторов, 2022
© Оформление РИЦ «Школа», 2022

## ФДББС ШАРТЛАРЫНДА ЭЗЛӘНҮ – ТИКШЕРЕНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ

**Закиров Айдар Миңлекәшиф улы**
**Мансуров Алмаз Илдар улы**
*МАББУ «7нче лицей-интернат»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

Укыту системасы күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерде. ФДББС килеп керде, шуңа бәйле рәвештә безнең эшчәнлегебез дә башкачарак алып барыла. Элеге эшебездә, үзебезнең эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенең үзенчәлекләре турында уртаклашасы килде. Әлеге эшебезнең актуальлеген безнең бу юнәлештә куйган хезмәтебез һәм шуның нигезендә ирешелгән нәтиҗәләр билгели.

Шулай итеп, федераль белем бирү дәүләт стандартларын өйрәнеп чыкканнан соң, без үз алдыбызга андагы бик күп таләпләр арасыннан, эзләнү-тикшеренү эшенә кагылышлы берничә таләпне аерып чыгардык.

Беренчедән, эзләнү-тикшеренү эше конкрет булырга тиеш. Аның конкрет объекты, без күрә алырдай, тотып карый алырдай, ишетә алырдай берәр предмет, образ, халәт һ.б. булырга тиеш.

Икенчедән, ул һәрвакыт нинди дә булса социаль әһәмияткә ия. Әһәмиятле эш булмаса, укучыларның бу эш белән шөгыльләнәсе килмәс иде.

Өченчедән, мәгълүмати, гамәли проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән. Мәсәлән, Болак күперләренең тарихын, килеп чыгышын, архитектур үзенчәлекләрен, берәр шәхес турында, ниндидер тарихи объект турында ялгыш фикер булу – ул мәгълүмати проблема. Җәмгыятьтә капма-каршы фикерләрне дә шундый проблемалар рәтенә кертә алабыз. Аларны хәл итү, тикшеренү эше вакытында төгәллек кертү безнең максат булып тора.

Дүртенче таләп – тикшеренүләр үткәрү. ФББДС укучының тикшеренү үткәрүен таләп итеп куя. Ул нәрсәне дә булса өйрәнергә, тотып карарга, ишетергә, аның турында мәгълүмат тупларга тиеш.

Үзебез дә сизмәстән, киләсе таләпкә дә күчтек. Мәгълүмат эзләү төрле-төрле булырга мөмкин, ул интернетта, китапханәдә, я булмаса кемнәрдән дә булса сораштыру һ.б. Мәгълүмат эзләү ул бер фән буенча (әдәбият яки туган тел) буенча гына бармый, төрле фәннәрне дә үз эченә ала. Бу – предметара бәйләнешләрне барлыкка китерә Мәсәлән, Һади Такташны өйрәнгәндә, география, тарихка һәм башка фәннәргә кагылып китәргә мөмкин.

Эшне тәкъдим итү – эшне яклау, күрсәтү рәвешендә башкарыла. Укучы үзенең эшен тәкъдим итә белергә, аның әһәмиятен аңларга тиеш. Эшне яклаганда, ул эшенең бөтен үзенчәлекләрен белергә, аны ни өчен эшләгәнен аңларга тиеш. Гади генә итеп әйткәндә, нинди сорау гына бирсәң дә, җавап бирә белүе шарт.

• Ни өчен без нәкъ менә шушы таләпләрне аерып чыгардык соң? ФДББС таләп иткәнчә, алар баланы актив эшчәнлеккә тарта. Шушы тәртиптә эшне оештырсак, бала үзе белем ала дигән сүз бу. Ә баланы актив эшчәнлеккә тарту өчен нәрсәләр кирәк? Кызыклы тема кирәк. Тема балада кызыксыну уятмаса, ул аның белән шөгыльләнмәячәк. Мисал өчен, укучылар Горький паркындагы Һади Такташның кабер ташын, Рөстәм Миңнехановның малае каберен күреп кайттылар. Сорау туа: «Ни өчен элек зират булган, ә хәзер – парк? Парк уртасында кеше күмелгәнме?». Шуннан чыгып, укучыга зиратларга багышлап тема тәкъдим итәргә була. Безнең Татар зираты турында «Мәңгелеккә күчкән тарих» дигән эшебез бар инде. Тема үзенчәлекле. Анда гадәти булмаган (Рөстәм Нургали улы Миңнехановның малаеның паркка күмелүе) элемент бар.

• Тема чагыштырмача тиз үтәлергә тиеш. Озакка сузылган эшкә карата кызыксыну кими, нәтиҗәсе дә начар була.

• Тема яшь үзенчәлекләренә туры килсен. Мәсәлән, Такташның мәхәббәт лирикасын, конкрет алсак, «Мәхәббәт тәүбә» сен 7 нче сыйныф укучысына бирсәк, анда кызны алдауларын, аның ана булуын ул аңлап бетермәс, яки дөрес аңламас. Икенче мисал, 11 нче сыйныф укучысы тылсымлы экиятләрне өйрәнсә, аңа да бу эш бик кызык булмас кебек.

• Теләкләр мөмкинлекләргә туры килүе шарт. Без һәрвакыт үзебез күрә алырдай, үзебез бара алырдай, тикшерә алырдай әйберне өйрәнәбез. Ничек кенә теләсәк тә, Париждагы Эйфель манарасын өйрәнә алмыйбыз, чөнки мөмкинлекләребез юк.

• Эшне сузмаска, тема табылуга башларга кирәк. Балада нәрсәгә дә булса кызыксыну туса, аны борып җибәрергә ярамый, тыгыз эш графигына карамастан аның белән шөгыльләнергә кирәк.

Баланы актив эшчәнлеккә тарту өчен төп кирәк әйбер – аның кызыксынуы икәнен аңладык. Кызыксынуны ничек уятырга соң?

Нәрсәгә дә булса игътибар, кызыксыну өч әйбер: күрү, ишетү һәм тактиль органнар ярдәмендә формалаша. Тактиль органнар дип үзебезне шул мөхиттә тою, әйләнә-тирәне кешедә булган барлык тоемлаулар белән кабул итүне атыйбыз.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, әгәр дә мәгълүматны кабул итүне һәм кызыксынуны шартлы рәвештә «М» хәрефе дип алсак, ишетү органнары

– М*1, күрү органнары – М*5, тактиль органнар М*13 булыр иде. Ягъни, тактиль органнар мәгълүматны 13 тапкырга күбрәк кабул итә. Бу алар ярдәмендә кызыксыну уяту җиңелрәк һәм эффектлырак була дигән сүз. Бу алымны шартлы рәвештә күреп өйрәнү (истә калдыру) методы дип атыйбыз һәм шуны кулланырга тырышабыз.

Гомумиләштереп әйткәндә, ФББДС дөрес аңлау, эзләнү-тикшеренү эшләрен тиешенчә һәм кызыклы итеп оештырырга ярдәм итә.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ СӘНГАТЬЛЕ СӨЙЛӘМЕНӘ ИРЕШҮ ЮЛЛАРЫ

**Захарова Альбина Алексей кызы**
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы*
*Осиново бистәсенең «В.В.Карпов исемендәге лицей»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Педагогик эшчәнлек – аңлы һәм максатлы рәвештә алып барыла торган тәрбияви күренеш, һәм ул җәмгыятьнең иң мөһим бурычларның берсе. Без әнә шундый бурычларны куйган җәмгыятьтә яшибез. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына бурычлар икеләтә арта. Беренчедән, тел мөгаллиме балаларга белем бирә, тәрбия кыла; икенчедән, туган тел аша яшь буынга халыкның бай рухи мәдәниятен, аның дөньяны танып белүен, идеалларын, халыкның озак еллар буе тупланган белемен һәм тормыш тәҗрибәсен тапшыра.

Әйе, дөрестән дә, туган телне һәм әдәбиятны укыту кебек җаваплы фән юктыр ул. Ник дисәң, без, тел мөгаллимнәре алдында, белем һәм күнекмә бирүдән тыш, туган теленә, халкына олы һәм саф мәхәббәт хисен тәрбияләү, гореф-гадәтләрен өйрәтү, милли үзаң, иман-әхлак сеңдерү бурычы да тора. Минемчә, һәр татар теле һәм әдәбияты укытучысының төп бурычы – укучыда эчке матурлыкта омтылыш тәрбияләү, әйләнә-тирә мохиткә, дөньядагы төрле вакыйгаларга дөрес бәя бирү. Аралаша белүнең төп шарты – бала күңелендә китапка мәхәббәт тәрбияләү.

Тел дәресләрен күбрәк проблемалы, иҗади эзләнү – тикшеренү рәвешендә үткәрергә тырышу да эзсез калмый: укучыларымның кыю үз фикерләре, үз тормыш позицияләре сиздерә.

Сүз байлыгын арттыру һәм әдәби телдә сөйләргә өйрәтү – укучылар сөйләмен үстерүдәге икенче юнәлеш. Өченче юнәлеш – фикерне телдән һәм язма рәвештә әйтә белергә өйрәтү.

**Яңалыкка омтылу – заман таләбе**

**Акашина Н.М., Каримова Ф.И.** Работа над орфографической зоркостью в рамках школьного проекта «Грамотность на кончике пера» «Ак китап» – «Белая книга» ........................................................111

**Галәветдинова Л.Г., Ибраһимова Э.С.** Мәктәптә заманча цифрлы белем бирү мохите ........................................................................................ 114

**Гәрәева Л.И., Гәрәева А.З.** Туган тел дәресләрендә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә инновацион һәм үстерелешле укыту технологияләре аша укучыларның сөйләм телен үстерү ................................................... 118

**Гәрәева Л.И., Гәрәева А.З.** Дәрестән тыш эшчәнлек .......................... 121

**Гильметдинова А.Д.** Татар теле дәресләрендә флэш-карталар белән эшләү алымнары ........................................................................................ 124

**Закиров А.М., Мансуров А.И.** ФДББС шартларында эзләнү – тикшеренү эшчәнлеген оештыру............................................................... 126

**Захарова А.А.** Укучыларның сәнгатьле сөйләменә ирешү юллары ......................................................................................... 128

**Мәҗитова А.Л.** Мәгълүмати җәмгыятьтә медиакультура..................... 130

**Низамиева А.Н.** Дәрестән тыш эшчәнлек – белем бирү процессының аерылгысыз өлеше ..................................................................................... 133

**Сафина Р.Р.** Әдәби әсәрне өйрәнгәндә концептуальләштерү технологиясе ............................................................................................. 138

**Фазулова Г.И.** Дәрестән тыш эшчәнлекне оештырганда лэпбук алымының әһәмияте....................................................................... 139

**Шаева В.М.** Padlet.com – дистанцион укытуның бер чарасы............... 142

**Шәйдуллина Л.М.** Г. Тукай һәм вакытлы матбугат: «Мирасханә» сайтына күзәтүләрдән...................................................... 143

**Инклюзивное образование: от понятия к образовательной практике**

**Березина Л.Г., Емельянова М.Н., Калинин В.С.** Использование игровых технологий в социально-эмоциональном развитии детей с РАС на базе ресурсного класса ........................................................... 147

**Мәрданшина Р.М.** Сүзләрнең иҗек төзелеше: коррекцияләү буенча күнегүләр системасы ........................................... 152

# *ЛИСТАЯ СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ…*

**Республиканские педагогические чтения,
посвященные выдающимся татарским
просветителям, педагогам
и общественным деятелям**

Техническое редактирование
и компьютерная верстка – *Азат Гапсаламов*

Сдано в набор 14.01.2023 г. Подписано к печати 30.01.2023.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Таймс». Печать цифровая.
Усл. печ. 28,37 л. Печ. 30,5 л. Заказ № 308.

420111, Казань, Дзержинского, 9/1. Тел. 8 917-264-8483.
Отпечатано в редакционно-издательском центре «Школа».
E-mail: ric-school@yandex.ru